Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Полянка авыл җирлеге Советы

К А Р А Р
№ 92
31.08.2020 ел.

Бюджет процессын оештыру өлешендә җирле
әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең
бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Аграмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 2019 елның 16 июлендәге 67-1 номерлы Полянка авыл җирлеге Советы карары нигезендә. «Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында», Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу өлешендә бирергә.
2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 п. күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны билгеләнгән вакытта Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Полянка авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Сибгатуллина